ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2020 елның 29 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгы турында» 2001 елның 24 гыйнварындагы 595 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2001, № 1 – 2; 2005, № 1 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2010, № 5 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) преамбулада «милекчеләре, аларны биләүчеләр, алардан файдаланучылар, шул исәптән аларны арендалаучылар» сүзләрен «милекчеләре, җирдән файдаланучылар, җир биләүчеләр һәм җир кишәрлекләрен арендалаучылар» сүзләренә алмаштырырга;

2) 1 статьяда:

а) дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын торгызу – мелиоратив һәм башка чараларны үткәрү юлы белән авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын саклап калу һәм арттыру;»;

б) җиденче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

в) унынчы – уникенче абзацларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

г) ундүртенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

д) унбишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«агрохимик хезмәт күрсәтү – авыл хуҗалыгы җирләренә караган җир кишәрлекләре милекчеләрен, җирдән файдаланучыларны, җир биләүчеләрне һәм җир кишәрлекләрен арендалаучыларны агрохимикатлар, технологияләр, техника белән тәэмин итү эшчәнлеге, шулай ук авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын торгызу буенча чаралар һәм авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын тәэмин итү өлкәсендә фәнни тикшеренүләр үткәрү эшчәнлеге;»;

3) 3 статьяда:

а) исемендә «милекчеләренең, аларны биләүчеләрнең, алардан файдаланучыларның, шул исәптән аларны арендалаучыларның» сүзләрен «милекчеләренең, җирдән файдаланучыларның, җир биләүчеләрнең һәм җир кишәрлекләрен арендалаучыларның» сүзләренә алмаштырырга;

б) беренче абзацта «милекчеләре, аларны биләүчеләр, алардан файдаланучылар, шул исәптән аларны арендалаучылар» сүзләрен «милекчеләре, җирдән файдаланучылар, җир биләүчеләр һәм җир кишәрлекләрен арендалаучылар» сүзләренә алмаштырырга;

в) икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«федераль законнарда каралган мәҗбүри чаралар үткәрү белән беррәттән авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын торгызу буенча чаралар үткәрергә;»;

г) түбәндәге эчтәлекле яңа өченче абзац өстәргә:

«федераль законнарда каралган мәҗбүри тикшеренүләр үткәрү белән беррәттән авыл хуҗалыгы җирләренә туфрак, геоботаник һәм башка тикшеренүләр үткәрергә;»;

д) өченче һәм дүртенче абзацларны тиешенчә дүртенче һәм бишенче абзацлар дип санарга;

е) бишенче абзацны алтынчы абзац дип санарга һәм анда «хокукларга ия булырга» сүзләрен «хокукларны гамәлгә ашырырга» сүзләренә алмаштырырга;

4) 4 статьяда:

а) исемендә «милекчеләренең, аны биләүчеләрнең, аннан файдаланучыларның, шул исәптән аларны арендалаучыларның» сүзләрен «милекчеләренең, җирдән файдаланучыларның, җир биләүчеләрнең һәм җир кишәрлекләрен арендалаучыларның» сүзләренә алмаштырырга;

б) беренче абзацта «милекчеләре, аны биләүчеләр, аннан файдаланучылар, шул исәптән аларны арендалаучылар» сүзләрен «милекчеләре, җирдән файдаланучылар, җир биләүчеләр һәм җир кишәрлекләрен арендалаучылар» сүзләренә алмаштырырга;

в) түбәндәге эчтәлекле яңа өченче абзац өстәргә:

«авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын торгызу буенча чараларны мондый чараларны үткәрүнең федераль законнар нигезендә төзелгән планына ярашлы рәвештә үткәрүне тәэмин итәргә;»;

г) өченче һәм дүртенче абзацларны тиешенчә дүртенче һәм бишенче абзацлар дип санарга;

д) бишенче абзацны алтынчы абзац дип санарга һәм аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«федераль законнар белән вәкаләтләр бирелгән затларның авыл хуҗалыгы җирләренә туфрак тикшеренүләре, геоботаник һәм федераль законнарда каралган башка тикшеренүләр үткәрүләре өчен җир кишәрлекләренә үтеп керә алуын тәэмин итәргә;»;

е) алтынчы һәм җиденче абзацларны тиешенчә җиденче һәм сигезенче абзацлар дип санарга;

5) 7 статьяда:

а) икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын торгызу чараларын үз эченә алган Татарстан Республикасы дәүләт программаларын әзерләү һәм гамәлгә ашыру;»;

б) бишенче абзацта «милекчеләрен, аларны биләүчеләрне, алардан файдаланучыларны, шул исәптән аларны арендалаучыларны» сүзләрен «милекчеләрен, җирдән файдаланучыларны, җир биләүчеләрне һәм җир кишәрлекләрен арендалаучыларны» сүзләренә алмаштырырга;

в) тугызынчы абзацта «торгызу» сүзен «рекультивацияләү» сүзенә алмаштырырга;

г) унынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын торгызу буенча чаралар үткәрү планнарын әзерләү;»;

6) 10 статьяның беренче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгы торышы күрсәткечләрен дәүләт исәбенә алу авыл хуҗалыгы җирләренә туфрак, геоботаник һәм башка тикшеренүләр нәтиҗәләрен җыюдан һәм гомумиләштерүдән гыйбарәт.»;

7) 11 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11 статья. **Агрохимик хезмәт күрсәтү**

Агрохимик хезмәт күрсәтү авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын тәэмин итү өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыручы юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар тарафыннан башкарыла.

Әлеге статьяның беренче өлешендә күрсәтелгән затлар үзләренең эшкуарлык эшчәнлеген координацияләү, гомуми мөлкәти мәнфәгатьләрне күрсәтү һәм яклау максатларында граждан законнары нигезендә ассоциацияләр (берлекләр) төзергә хокуклы.»;

8) 12 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12 статья. **Агрохимик хезмәт күрсәтүнең төп юнәлешләре**

Агрохимик хезмәт күрсәтүнең төп юнәлешләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

авыл хуҗалыгы җирләре уңдырышлылыгына туфрак, геоботаник һәм башка тикшеренүләр һәм мониторинг үткәрү;

авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын торгызу буенча чаралар үткәрү;

авыл хуҗалыгы җирләренә караган җир кишәрлекләре милекчеләрен, җирдән файдаланучыларны, җир биләүчеләрне һәм җир кишәрлекләрен арендалаучыларны агрохимикатлар белән тәэмин итү;

авыл хуҗалыгы җирләренә караган җир кишәрлекләре милекчеләренә, җирдән файдаланучыларга, җир биләүчеләргә һәм җир кишәрлекләрен арендалаучыларга авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын торгызу буенча чаралар үткәрү өчен техника бирү.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2020 ел, 13 ноябрь
№ 70-ТРЗ